Scientific Chronicles of the Turkic World
Төрки дөнья фәнни хроникасы
Научная хроника тюркского мира

# LATEST EVENTS IN THE SECOND HALF OF 2017

**On August 2 and 3, 2017**, Kazan hosted the 6th Session of the World Congress of Tatars. Eight hundred and eleven delegates from forty one countries took part in its work. At the Plenary Session of the Congress, the creation of the "Milli Shura" National Council was initiated and its membership was approved. Vasil Shaykhraziev, the Deputy Prime Minister of Tatarstan, was elected Chairman of the "Milli Shura" National Council. The created structure aims to develop the strategy of the Executive Committee of the World Congress of Tatars.

---

The World Tatar Congress hosted a presentation of a unique project developed by the Tatar Book Publishers - the "Center for Tatar Literature", which was created with the support of the Government of the Republic of Tatarstan and the Public Corporation "Tat-Media". The site *www.tatkniga.ru* is meant to be a platform for the audience interested in Tatar literature. This unique resource acquaints its users with the original culture and history of the Tatar people, the wisdom of Tatar writers and poets, and the beauty of the Tatar language.

In the "Library" section you can read a book of your choice for free. The main advantage of the portal is the possibility to read books in digital format.

The task of the project is to support Tatar literature and maintain our contemporaries' interest in it. The creators of the center are planning to produce audiobooks, which record the voices of famous presenters.

---

The All-Russian Scientific and Practical Conference "Karim Tinchurin and the Tatar Theater" was held on **September 14, 2017,** in the small hall of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan. The event was organized by the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, and the K. Tinchurin Tatar State Drama and Comedy Theater. The conference was timed to the 130th birth anniversary of the outstanding playwright.

The welcoming speeches were made by Deniya Zagidullina, the Vice-President of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, Kim Minnullin, the Director of the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibrahimov, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, and Fanis Musagitov, the Director of the Tatar State Drama and Comedy Theater named after K. Tinchurin.

The purpose of the conference was to find and develop new approaches to studying the life and work of Karim Tinchurin, who made a great contribution to the development of Tatar theater art, and to draw

public attention to his heritage. The program of the conference touched upon the major issues of Tatar theatre, the interactions of cultures through Karim Tinchurin's rich oeuvre, the theory and history of the drama, music, and scenography development. It also aimed to promote the works of this outstanding dramatist in the field of pedagogy.

The conference was attended by the representatives of Kazan (Volga Region) Federal University, the Kazan State Institute of Culture, teachers, students, and post-graduates of theatrical and other educational institutions, representatives of Tatar drama theaters, members of the Union of Writers of the Republic of Tatarstan, etc.

Moreover, in the foyer of the small hall of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, an exhibition was organized, displaying publications devoted to the life and work of Karim Tinchurin, archival materials, personal belongings of the classic – the valuable exhibits, which are kept in the museums of the drama theaters of the Republic of Tatarstan.

---

**On September 22-25, 2017,** the cities of Tyumen and Tobolsk hosted the All-Russian Scientific and Practical Conference "Historical and Cultural Heritage of the Tatars and Siberian Tatars from the Tyumen Region".

The scientific forum, organized by Tyumen State University, the Center for Tatar Culture of the Tyumen Region, and the Center for Siberian-Tatar Culture of Tobolsk, was attended by the scholars, historians, and representatives of regional authorities and public organizations of the Tyumen region, Kurgan, Chelyabinsk, Tatarstan, Crimea, and Moscow. At the conference, the Republic of Tatarstan was represented by the researchers of the Sh. Marjani Institute of History, the Academy of Sciences of the RT, the A. H. Khalikov Institute of Archeology, the Academy of Sciences of the RT, and the Association of Tatar Entrepreneurs.

The main purpose of the conference was to discuss the issues and prospects for a comprehensive study, real preservation, professional museumification, and practical use of the objects of the historical and cultural heritage of the Tatars.

---

**October 1** marked the 105th birth anniversary of the outstanding Russian scientist, historian, geographer, turkologist, and great humanist Lev Nikolaevich Gumilev. On this memorable date, a number of events took place in St. Petersburg: the laying of flowers at the monument to L. N. Gumilyov; gala evenings "He saw the path of peoples and epochs", "In search of the unfabled Lev Gumilyov", the show of the film "Resurrect, Die, and Live ...", and the book-illustrated exhibition "Lev Nikolayevich Gumilev - a historian, writer, and orientalist".

On October 2, in the Museum of Lev Gumilyov, the Round Table "Lev Gumilev Today: Problems of Perception, Understanding, and Development" was held, attended by Gumilyov's disciples, followers of his scientific school, as well as major St. Petersburg scholars involved in the research on the scientific problems posed by Gumilev.

On October 14, within the framework of the project "Tatar Sitting-Room", the Gumilev Readings were organized by the Permanent Mission in the Library of National Literatures. The jubilee events were also held in the National Cultural House "Luch-Nur" in Krasnoye Selo.

In Kazan, in Petersburg Street, representatives of the Ministry of Culture of the Republic of Tatarstan, the Union of Writers of the Republic of Tatarstan, prominent public figures, writers, and poets took part in the ceremony of laying flowers to the monument to L. N. Gumilyov on October 2.

---

**On October 6-20, 2017,** the Blue Room of the Russian State Library of Arts hosted the exhibition "Moments and Eternity: Images of Tatars in the Photographs of the Late 19th **-** Early 20th Centuries". This unique collection from the Department of the Manuscripts and Rare Rooks of the National Library of the Republic of Tatarstan included historical photographs that have become valuable sources for studying the history and culture of the Tatar people. Group and individual pictures, showing people in the interiors of photo salons, against natural landscapes, in a home environment, were taken not only in Kazan,

but also in different regions of the Russian Empire. Each work reflects the attitude of the artist to the images in the photos, characterizes the reality of the people's being, tells about famous Tatar theologians, famous merchant dynasties, figures of culture and art, literature and science that left their mark on the history of the people. The photographs enable us to trace the changes in the life and consciousness of the traditionally Muslim population: European traditions were introduced and the influence of Russian culture increased. The photos show how the European fashion was combined with elements of a national costume, how hairstyles changed, and children's fashion gradually replaced the copies of adult clothing among the wealthy Tatars.

---

**From October 9 to 10,** the Ministry of Education and Science of the Republic of Tatarstan held the Days of Tatar Education in Turkey. Engel Fattakhov, the Minister of Education and Science of the Republic of Tatarstan, headed the delegation paying their friendly visit to Turkey. The representatives of the Republic of Tatarstan visited educational institutions of the Turkish Republic and Marmara University. They held roundtable discussions with the authorities from the National Education Administration of the Istanbul province, organized a meeting with the Tatar diaspora in the Cultural Centre for the Turkic-speaking peoples “Topkapi” and laid flowers at the monument to G. Tukay. They also took part in the presentation of the Atlas “Tartarika” in Istanbul, in the gallery of arts at the Dolmabahce Palace Museum. The Atlas was translated into Turkish on the initiative of the Consul General of the Republic of Turkey in Kazan. The project was implemented by the Union of Municipalities of the Turkic World and the Sh. Mardzhani Institute of History, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan.

---

**On October 10, 2017**, the 10$^{th}$ International Theological Scientific and Educational Conference **-** Galimjan Barudi’s Readings “Islamic Theology and Academic Islamic Studies: Cooperation and Development Prospects”, was held in Moscow. The conference was attended by Russian and foreign representatives of state and non-state educational and research institutions, leading centers of Islamic research, including Al-Azhar University (Egypt), Indonesia, Brunei, Iran, Kyrgyzstan, Kazakhstan, Uzbekistan, etc.

---

**Summit**

Leo Tolstoy Institute of Philology and Intercultural Communication, Kazan Federal University (hereafter IPIC KFU), was the host of the Languages and Cultures International Summit on **October 19-21, 2017.**

The opening session of the conference was held at 10.00 a.m. on October 19, 2017, in the assembly hall of KFU, Building No. 33 (2 Tatarstan Str.).

The Summit featured the following science events:

The International Conference “J. I. Baudouin de Courtenay and World Linguistics”. The conference included two symposiums: “Clinical Linguistics” and “Modern Technologies: CLIL and CALL”

The 8$^{th}$ International Scientific and Practical Conference “Preservation and Development of Native Languages in the Multinational State: Problems and Perspectives”. The conference was comprised of three symposiums: “CEFR for National Systems of Validation of Language Abilities”, “Modern Turkology: Problems and Perspectives”, and “Native Languages in a Multicultural Educational Environment”.

The International Scientific and Practical Conference “East and West: Literature and Art Culture”. The conference included the symposium “Comparative Studies of Literature”.

The International Scientific and Practical Conference “Art and Art Education in the Context of Intercultural Interactions”. The conference included the symposium “Preservation of Arts and Historical Environment of the Modern City as a Spiritual Factor of Culture”.

The focus areas of the Summit, which included four conferences, seven symposiums, round tables, master classes and 25 section meetings, were centered around the following issues:

- theoretical and methodological postulates of the Kazan Linguistic and Turkic Schools and their significance for modern studies;

- historical and comparative studies of languages and cultures;
- clinical linguistics;
- computational and applied linguistics;
- linguistic identity and linguistic worldview, development of bi- and multilingualism;
- bilingual education. CLIL (Content and Language Integrated Learning);
- linguodidactic testology and language testing experience;
- IT in language learning, CALL (Computer Assisted Language Learning);
- issues of art and art education in the context of intercultural interactions;
- preservation and development of the arts and historical environment in the city, etc.

More than 250 scholars, teachers and heads of educational institutions, employees of federal, regional and municipal education management bodies, as well as scientific and other institutions related to theoretical and practical study of the issues concerning the preservation and development of native languages and cultures, post-graduate students, undergraduates and students of higher and secondary schools took part in the Summit. The participants were from the Republic of Tatarstan, Moscow, St. Petersburg, Makhachkala, Vladimir, Krasnodar, Chelyabinsk, N. Novgorod, Kirov, Yakutsk and other near and far abroad countries: Azerbaijan, Armenia, Germany, Italy, Kazakhstan, China, Kyrgyzstan, Slovakia, the USA, Turkmenistan, Turkey, etc.

The Languages and Cultures International Summit facilitated the fruitful exchange of information and results of academic research among scientists from the regions of the Russian Federation and countries of the near and far abroad. Topical problems of modern linguistics related to the ideas of the Kazan Linguistic School, the issues concerning the development and preservation of languages and cultures, and art education were discussed during the Summit.

---

**On November 8-11**, 2017, the 7th International Forum "Islam in a Multicultural World" was held at the Institute of International Relations, History, and Oriental Studies of Kazan (Volga Region) Federal University. The Forum was attended by leading scientists, representatives of the Spiritual Administrations of Muslims from Russia, Islamic universities, and madrassas.

The organizers of the conference were: Kazan (Volga Region) Federal University, the Institute of Oriental Studies of the Russian Academy of Sciences, the Center for Islamic Studies of the Academy of Sciences of Tatarstan, the Spiritual Administration of Muslims of the Russian Federation, the Spiritual Administration of Muslims of the Republic of Tatarstan, the Bulgarian Islamic Academy, the Russian Islamic Institute, and the Moscow Islamic Institute.

A number of conferences and round tables were held within the framework of the forum: The International Conference "Muslim Countries in the System of Modern International Relations. Religion and State in the Middle East: Issues of Interaction"; The International Conference "Issues of Deradicalization of Youth in the Post-Soviet Space"; The state of the Muslim Community monitoring: "Islamic Radicalism in the Subjects of the Russian Federation" (in memory of E. M. Primakov); The round table "Key Issues of Turkology: Russia and the Turkic-Muslim World"; The round table "History and Textology of Islam"; The round table-presentation "Problems of the Economic Development in the Middle East"; The round table discussions devoted to the memory of S. Mardzhani: "Theological and Legal Thought of the Islamic World"; The round table "Muslim Urban Civilization".

*This information has been provided by R. N. Valiullin, the Permanent Representative of the Republic of Tatarstan in St. Petersburg and the Leningrad Region; M. M. Khabutdinova, Candidate of Philology, Associate Professor of the Institute of Philology and Intercultural Communication named after Leo Tolstoy, Kazan Federal University; E. Kh. Kadirova, Candidate of Philology, Associate Professor of the Institute of Philology and Intercultural Communication named after Leo Tolstoy, Kazan Federal University.*

# 2017 ЕЛНЫҢ II ЯРТЫСЫНДА БУЛГАН ВАКЫЙГАЛАР

**2017 нче елның 2-3 нче август** көннәрендә Бөтендөнья татар конгрессының VI съезды узды. Анда Татарстан Республикасыннан, Россия Федерациясенең 73 төбәгеннән һәм 41 чит илдән 811 делегат һәм 207 кунак катнашты. Съездның пленар утырышында Милли Шура оешты һәм аның составы сайлап куелды. Шураның рәисе вазифаларын башкару Татарстан вице-премьеры Васил Шәйхразиевка йөкләнде. Яңа төзелгән оешма Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының стратегиясе белән шөгыльләнәчәк.

---

Татарстан хөкүмәте, Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән, Татарстан китап нәшриятында «Татар әдәбияты үзәге» www.tatkniga.ru проекты эшли башлады.

Хәзер татар әдәбиятының бай мирасы белән дөньяның теләсә кайсы почмагында танышып була. Электрон китапханәдә китапларны бушлай укырга мөмкин, үзеңә ошаган китапларның басма вариантына заказ бирү мөмкинлеге дә бар. Портал көн саен тулыландырылып тора. Бүгенгә «Татар әдәбияты үзәге»ндә ике меңләп китап тупланган.

Сайтны кулланучылар саны көннән-көн артып тору да татар әдәбияты белән кызыксынучыларның күп булуын дәлилли. Биредә күңелгә хуш килерлек һәртөрле әдәбият белән танышырга була: тарихи, фәнни әдәбият, балалар китаплары, матур әдәбият, белешмәлекләр, дәреслекләр дә бар. Сайтның һәрбер кулланучысы аның эшчәнлегенә үз өлешен кертә ала. Татарстан китап нәшрияты «Татар әдәбияты үзәге» яки нәшрият эшчәнлегенә кагылышлы фикерләрне tki@tatkniga.ru адресына җибәрергә тәкъдим итә.

---

**2017 нче елның 14 нче сентябрендә** ТР Фәннәр академиясенең кече залында «Кәрим Тинчурин һәм татар театры» дип аталган Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе уздырылды. Чара, ТР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты һәм К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры белән берлектә, бөек драматургның тууына 130 ел тулу уңаеннан оештырылды.

Конференция кунакларын ТР Фәннәр академиясе вице-президенты Д. Заһидуллина, ТР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры К. Миңнуллин, К. Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры директоры Ф. Мөсәгыйтов сәламләде.

Конференциядә Кәрим Тинчурин шәхесе һәм иҗатына бәйле көнүзәк проблемаларны ачыклау, милли театрлар репертуары тарихында аның иҗатын барлау, драматург әсәрләрен аңлауда музыка һәм сәхнә бизәлешенең өлеше хакында фәнни чыгышлар ясалды. Фәнни-гамәли конференция эшендә Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы, Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан дәүләт мәдәният институты, фәнни оешмалар, театр сәнгате белән бәйле уку йортлары, Татарстан театрлары, ТР Милли музее, архив хезмәткәрләре, ТР Язучылар берлеге һәм матбугат вәкилләре, аспирантлар, студентлар катнашты. Әлеге чарага театр сәнгатендә күренекле урын тоткан драматурглар һәм театр тәнкыйтьчеләре дә килгән иде. Моннан тыш, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең кече зал фойесында Кәрим Тинчурин шәхесенә багышланган фәнни басмалар, театр афишалары һәм буклетлар, музей экспонатлары һәм драматургның шәхси әйберләреннән торган күргәзмә эшләде.

---

**2017 нче елның 22-25 нче сентябрь** көннәрендә Төмән һәм Тубыл шәһәрләрендә «Татарларның һәм Төмән өлкәсе себер татарларының тарихи-мәдәни мирасы» дип аталган Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе булып үтте.

Төмән дәүләт университеты, Төмән өлкәсе татар мәдәнияте үзәге һәм Тубыл себер татарлары мәдәнияте үзәге җирлегендә уздырылган фәнни форумда Төмән өлкәсе, Курган, Чиләбе,

Татарстан, Кырым һәм Мәскәүдән галимнәр, тарихчылар, төбәкнең хакимият органнары һәм җәмәгать оешмалары вәкилләре катнашты. Татарстан Республикасын конференция эшендә ТР Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге тарих институты, ТР Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исемендәге археология институты галимнәре һәм Татар эшмәкәрләре ассоциациясе тәкъдим итте.

Конференциянең төп максаты булып татарларның тарихи-мәдәни мирасы объектларын комплекслы өйрәнү, реаль саклап калу, һөнәри музейлаштыру һәм гамәли файдалану мәсьәләләре һәм киләчәге хакында фикер алышу торды.

---

**1 нче октябрьдә** күренекле рус галиме, тарихчы, географ, тюрколог, бөек гуманист Лев Николаевич Гумилевның тууына 105 ел тулды. Әлеге истәлекле көн уңаеннан Санкт-Петербургта берничә чара узды: Л.Н. Гумилев һәйкәленә чәчәкләр кую; «Ул халыклар һәм гасырлар юлын күрде» («Он видел путь народов и веков»), «Уйлап чыгарылмаган Лев Гумилевны эзләп» («В поисках невымышленного Льва Гумилева») дип аталган тантаналы кичәләр, «Яңадан туарга, үләргә һәм яшәргә…» («Воскресать, умирать и жить…») фильмын күрсәтү; «Лев Николаевич Гумилев – тарихчы, язучы, Шәрык белгече» дип исемләнгән китап һәм иллюстрацияләр күргәзмәсе.

2 нче октябрьдә Лев Гумилев музеенда «Лев Гумилев бүген: кабул итү, аңлау, үстерү мәсьәләләре» түгәрәк өстәле булып узды, һәм анда Гумилевның укучылары, фәнни мәктәбе дәвамчылары, шулай ук Петербургның Гумилев тарафыннан куелган фәнни мәсьәләләрне тикшерү белән шөгыльләнүче зур галимнәре катнашты.

2 нче октябрьдә Лев Гумилевның Казан шәһәре үзәгендә – Петербург урамы башында куелган һәйкәленә республика җәмәгатьчелеге чәчәкләр салды. Бөек тарихчыны зурларга татар язучылары һәм татар галимнәре аеруча күп килгән иде. Чарада Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, ТР Язучылар берлеге вәкилләре, күренекле җәмәгать эшлеклеләре, язучылар һәм шагыйрьләр катнашты.

14 нче октябрьдә, «Татар кунак бүлмәсе» проекты кысаларында, Санкт-Петербургның Милли әдәбиятлар китапханәсендә Даими вәкиллек тарафыннан оештырылган Гумилев укулары булып узды. Юбилей чаралары шулай ук Красное Село шәһәрендәге «Луч-Нур» милли-мәдәни йортында да үткәрелде.

---

Россия дәүләт сәнгать китапханәсенең Зәңгәр залында **2017 нче елның 6-20 нче октябрендә** «Мизгел һәм мәңгелек: Татарстан Милли китапханәсе фондыннан XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татарлар фотосурәтләрдә» дигән күргәзмә эшләде. Анда Татарстан Милли китапханә фондларында саклана торган борынгы фотолар белән танышу мөмкинлеге булды. Күргәзмәнең максаты – китапханә фондларындагы үзенчәлекле коллекцияләрне, Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасын күрсәтү һәм популярлаштыру.

Экспозиция үз эченә 132 хезмәтне берләштерә, һәм монда китапханәнең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге коллекцияләрендәге XIX гасыр ахыры һәм XX гасыр башына караган үзенчәлекле фотографияләр тәкъдим ителә. Хәзерге вакытта коллекциядә Казан, татар халкы тарихын чагылдырган 1500 дән артыграк фотосурәт саклана. Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге җитәкчесе Айрат Зәһидуллин белдергәнчә, коллекциянең үзенчәлекле өлешен Ш. Мәрҗани, Г. Камал, Р. Фәхретдин, шулай ук татарның яшь сәүдәгәрләре, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөгаллимнәре, шәкертләре һәм башкаларның фотосурәтләре тәшкил итә.

---

**9-10 нчы октябрь** көннәрендә Татарстан Мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов җитәкчелегендәге төркем Төркиядә татар мәгарифе көннәре уздырды. Алар Төркиянең мәгариф оешмаларында, Мәрмәрә университетында булдылар, шулай ук Истанбул провинциясенең милли

мәгариф идарәсе вәкилләре белән берлектә «түгәрәк өстәл» уздырдылар, Топкапы төрки телле халыклар мәдәни комплексында татар диаспорасы белән очраштылар, Тукай һәйкәленә чәчәкләр куйдылар.

10 нчы октябрьдә әлеге делегация Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры Рафаиль Хәкимов җитәкчелегендәге татар галимнәре белән берлектә Истанбулның Долмабахче сәнгать комплексында узган презентациядә катнашты**.** Анда «Tartarica» тарихи атласы тәкъдим ителде.

Делегация Истанбул каласында Төрек дөньясының муниципалитетлар берлегендә дә (TDBB) булды. Әлеге берлек 2003 нче елдан бирле эшли. Монда 28 илдән 1140 әгъза-муниципалитет исәптә тора. Берлек эшчәнлегенең бер тармагы – мәдәни-белем өлкәсендәге проектларны дөньякүләм дәрәҗәдә тормышка ашырырга ярдәм итү. Нәкъ менә алар ярдәмендә «Тартарика» төрек теленә тәрҗемә ителде.

Татар галимнәре берлекнең генераль секретаре, доктор Фәхри Солак белән очрашкач, ул, «Tartarica» атласын төрек теленә тәрҗемә итәргә мөмкинлек биргән өчен, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтына Төрек дөньясының муниципалитетлар берлеге исеменнән олы рәхмәтен җиткерде.

Белешмә: «Тартарика» тарихи атласына Татарстанның табигый байлыклары, тарихы, мәдәнияте, этнографиясе, икътисады, муниципаль берәмлекләре турында мәгълүматлар тупланган. Монда Евразиянең киң территориясендә төрле тарихи чорларда яшәгән төрки халыклар тарихы яктыртыла. Татар халкының тарихы, этнографиясе, мәдәнияте хакында этрафлы мәгълүмат бирелә. Идел буе Болгары һәм Алтын Урда халыкларының ислам кабул итүе турында да язылган. Басма төбәкнең тарихы һәм географиясе буенча борынгы һәм заманча карталарны, уникаль иллюстрацияләрне үз эченә ала.

---

**2017 нче елның 10 нчы октябрендә** Мәскәү шәһәрендә X Халыкара теология фәнни-укыту конференциясе – «Ислам теологиясе һәм академик ислам белеме: хезмәттәшлек һәм үсеш перспективалары» темасына Галимҗан Баруди исемендәге укулар булып узды. Конференция эшендә Россия һәм чит илләрдән, шул исәптән Әл-Әзхар университеты (Мисыр), Индонезия, Бруней, Иран, Кыргызстан, Казахстан, Үзбәкстан һ.б. илләрдән дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган белем бирү һәм фәнни-тикшеренү оешмалары, ислам тикшеренүләре буенча әйдәп баручы үзәкләрнең вәкилләре катнашты.

---

**2017 нче елның 19-21 нче октябрендә** Казан федераль университетының Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты КФУның кече инновация предприятиесе «Лингвистика консалтинг үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән берлектә Телләр һәм мәдәниятләр халыкара саммитын уздырды. Саммит кысаларында түбәндәге фәнни чаралар оештырылды: «И.А. Бодуэн де Куртенэ һәм дөньякүләм лингвистика» Халыкара конференциясе; «Клиник лингвистика» симпозиумы; «CLIL һәм CALL заманча технологияләре» симпозиумы; «Күпмилләтле дәүләт шартларында туган телләрне саклау һәм үстерү: проблемалар һәм перспективалар» VIII Халыкара фәнни-гамәли конференциясе; «Тел белүне бәяләү милли системалары өчен CEFR» симпозиумы; «Хәзерге тюркология: проблемалар һәм перспективалар» симпозиумы; «Күпмәдәниятле белем бирү мохитендә туган телләр» симпозиумы; «Шәрык-Гареб: әдәбият һәм сәнгати мәдәният» Халыкара фәнни-гамәли конференциясе; «Әдәби компаративистика» симпозиумы; «Мәдәниятара багланышлар контекстында сәнгать һәм сәнгати белем» Халыкара фәнни-гамәли конференциясе; «Мәдәниятнең рухи факторы буларак, хәзерге шәһәрнең сәнгати-тарихи тирәлеген саклау» симпозиумы.

---

**2017 нче елның 8-11 нче ноябрендә** Казан (Идел буе) федераль университетының Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институтында «Мультимәдәни дөньяда ислам» дип

аталган VII Халыкара форум узды. Форумда әйдәп баручы галимнәр, Россия мөселманнарының Диния нәзарәте, ислам вузлары, мәдрәсәләрдән вәкилләр катнашты.

Конференцияне оештыручылар: Казан (Идел буе) федераль университеты, Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институты, Татарстан Фәннәр академиясенең Исламны өйрәнү үзәге, Россия Федерациясе мөселманнарының Диния нәзарәте, Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте, Болгар ислам академиясе, Россия ислам институты, Мәскәү ислам институты.

Форум кысаларында түбәндәге конференция һәм түгәрәк өстәлләр эшләде: «Хәзерге халыкара мөнәсәбәтләр системасында мөселман илләре. Якын Көнчыгышта дин һәм дәүләт: үзара йогынты ясау мәсьәләләре» Халыкара конференциясе; «Советлар чорыннан соң яшьләрнең радикаллашуы мәсьәләсе» Халыкара конференциясе; Мөселман җәмгыяте халәтенә мониторинг: «РФ субъектларында ислам радикализмы» (Е.М. Примаков истәлегенә); «Тюркологиянең актуаль мәсьәләләре: Россия һәм төрки-мөселман дөньясы» түгәрәк өстәле; «Ислам тарихы һәм текстологиясе» түгәрәк өстәле; «Якын Көнчыгышның икътисади үсеше мәсьәләләре» түгәрәк өстәл-презентациясе; «Ислам дөньясының дини һәм хокукый фикере» дип аталган Ш. Мәрҗани истәлегенә түгәрәк өстәл; «Мөселман шәһәр цивилизациясе» түгәрәк өстәле.

*Материаллар түбәндәге кешеләр тарафыннан җыелды һәм әзерләнде: Татарстан Республикасының Санкт-Петербург һәм Ленинград өлкәсендәге даими вәкиле Р.Н. Вәлиуллин; филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университетының Л.Н. Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты доценты М.М. Хәбетдинова; филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университетының Л.Н. Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты доценты Э.Х. Кадыйрова.*

# ПРОШЕДШИЕ СОБЫТИЯ II ПОЛОВИНЫ 2017 ГОДА

**2–3 августа 2017 года** в г. Казани состоялся VI съезд Всемирного конгресса татар, в работе которого приняли участие 811 делегатов и 207 гостей из Республики Татарстан, 73 регионов Российской Федерации и 41 зарубежной страны. На Пленарном заседании съезда было инициировано создание национального совета «Милли шура» и утвержден его состав. Председателем национального совета «Милли шура» был избран заместитель премьер-министра Республики Татарстан Василь Шайхразиев. Созданная структура будет заниматься разработкой стратегии Исполнительного комитета Всемирного конгресса татар.

---

На Всемирном конгрессе татар состоялась презентация уникального проекта Татарского книжного издательства «Центр татарской литературы», созданного при поддержке Правительства РТ, ОАО «Татмедиа». Сайт www.tatkniga.ru – это площадка для интересующейся татарской литературой аудитории. Этот уникальный ресурс знакомит с самобытной культурой и историей татарского народа, мудростью татарских писателей и поэтов, красотой татарского языка.

В разделе «Библиотека» можно прочитать бесплатно понравившуюся книгу. Главное преимущество портала – это возможность читать книги в цифровом формате.

Задача проекта – поддержать татарскую литературу и интерес к ней у современников. В планах создателей центра издание аудиокниг, в которых будут звучать голоса известных дикторов.

---

**14 сентября 2017 г.** в малом зале Академии наук Республики Татарстан прошла всероссийская научно-практическая конференция «Карим Тинчурин и татарский театр». Организаторами мероприятия выступили Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук РТ и Татарский государственный театр драмы и комедии им. К. Тинчурина. Конференция была приурочена к 130-летию со дня рождения выдающегося драматурга.

С приветственным словом выступили вице-президент Академии наук РТ Дания Загидуллина, директор Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук РТ Ким Миннуллин, директор Татарского государственного театра драмы и комедии им. К. Тинчурина Фанис Мусагитов.

Цель конференции – поиск и выработка новых подходов в изучении жизни и творчества Карима Тинчурина, который внес огромный вклад в развитие татарского театрального искусства, а также привлечение внимания общественности к его наследию. Программа конференции затронула актуальные проблемы татарского театра и взаимодействия культур через богатое творческое наследие Карима Тинчурина, вопросы теории и истории развития драматургии, музыки и сценографии, а также пропаганды выдающихся произведений драматурга в области педагогики.

В работе конференции приняли участие представители Казанского (Приволжского) федерального университета, Казанского государственного института культуры, преподаватели, студенты и аспиранты театральных и других образовательных учреждений, представители татарских драматических театров РТ, члены Союза писателей РТ и др.

Кроме того, в фойе малого зала Академии наук РТ была организована выставка изданий, посвященных жизни и творчеству Карима Тинчурина, архивных материалов, личных вещей классика – ценных экспонатов, которые хранятся в музеях драматических театров РТ.

---

**22–25 сентября 2017 г.** в гг. Тюмени и Тобольске прошла Всероссийская научно-практическая конференция «Историко-культурное наследие татар и сибирских татар Тюменской области».

На научном форуме, который состоялся на базе Тюменского госуниверситета, Центра татарской культуры Тюменской области и Центра сибирско-татарской культуры Тобольска, приняли участие ученые, историки, представители региональных органов власти и общественных организаций Тюменской области, Кургана, Челябинска, Татарстана, Крыма и Москвы. Республику Та-

тарстан представляли ученые Института истории им. Ш. Марджани АН РТ, Института археологии им. А. Х. Халикова АН РТ и Ассоциация татарских предпринимателей.

Основной целью конференции стало обсуждение вопросов и перспектив комплексного изучения, реального сохранения, профессиональной музеефикации и практического использования объектов историко-культурного наследия татар.

---

**1 октября** исполнилось 105 лет со дня рождения выдающегося русского ученого, историка, географа, тюрколога, великого гуманиста Льва Николаевича Гумилева. В рамках этой памятной даты в Санкт-Петербурге прошел ряд мероприятий: возложение цветов к памятнику Л. Н. Гумилеву; торжественные вечера «Он видел путь народов и веков», «В поисках невымышленного Льва Гумилева», показ фильма «Воскресать, умирать и жить…», книжно-иллюстрированная выставка «Лев Николаевич Гумилев – историк, писатель, востоковед».

2 октября в Музее Льва Гумилева состоялся Круглый стол «Лев Гумилев сегодня: проблемы восприятия, понимания, развития», где участвовали ученики Гумилева, последователи его научной школы, а также крупные петербургские ученые, занимающиеся разработкой поставленных Гумилевым научных проблем.

14 октября в рамках проекта «Татарская гостиная» в Библиотеке национальных литератур состоялись Гумилевские чтения, организованные Постоянным представительством. Также юбилейные мероприятия прошли и в Национально-культурном доме «Луч-Нур» в Красном Селе.

В церемонии возложения цветов 2 октября к памятнику Л. Н. Гумилева на ул. Петербургской в г. Казани приняли участие представители Министерства культуры РТ, Союза писателей РТ, видные общественные деятели, писатели и поэты.

---

**6–20 октября 2017 г.** в Голубом зале Российской государственной библиотеки искусств работала выставка «Мгновения и вечность: образы татар в фотографиях конца XIX – начала XX века». Представленная уникальная коллекция отдела рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан включала в себя исторические фотографии, ставшие ценными источниками для изучения истории и культуры татарского народа. Коллективные и индивидуальные снимки в интерьерах фотосалонов, на фоне природы, в домашней обстановке сделаны не только в Казани, но и в разных районах Российской империи. Каждая работа отражает отношение мастера к запечатленному объекту, характеризует реальность народного бытия, рассказывает об известных татарских богословах, знаменитых купеческих династиях, деятелях культуры и искусства, литературы и науки, оставивших свой след в истории народа. Фотографии помогают проследить, как менялись сознание и быт традиционно мусульманского населения: внедрялись европейские традиции, росло влияние русской культуры. Фотоснимки демонстрируют, как европейская мода соседствует с элементами национального костюма, как изменяются прически, в среде зажиточных татар появляется детская мода, пришедшая на смену копированию взрослой одежды.

---

С **9 по 10 октября** Министерство образования и науки РТ в Турции провело Дни татарского просвещения. Во главе делегации, посетившей Турцию с дружественным визитом, находился министр образования и науки РТ Энгель Фаттахов. Представители РТ посетили образовательные организации Турецкой Республики, Университет Мармара, провели круглый стол с руководством Управления национального образования провинции Стамбул, организовали встречу с татарской диаспорой в культурном комплексе тюркоязычных народов «Топкапы», а также возложили цветы к памятнику Г. Тукаю. Кроме того, приняли участие в церемонии презентации атласа «Тартарика» в Стамбуле, в галерее искусств музея дворца Долмабахче. Атлас был переведен на турецкий язык по инициативе Генерального Консула Турецкой Республики в Казани. Проект осуществлен Союзом Муниципалитетов тюркского мира и Институтом истории им. Ш. Марджани АН РТ.

---

**10 октября 2017 г.** в Москве состоялась X Международная теологическая научно-образовательная конференция – Чтения имени Галимджана Баруди на тему «Исламская теология и академическое исламоведение: сотрудничество и перспективы развития». В работе конференции приняли участие российские и иностранные представители государственных и негосударственных образовательных и научно-исследовательских учреждений, ведущих центров исламских исследований, Индонезии, Брунея, Ирана, Кыргызстана, Казахстана, Узбекистана, университета Аль-Азхар (Египет) и др.

---

Институт филологии и межкультурной коммуникации им. Льва Толстого Казанского федерального университета совместно с малым инновационным предприятием КФУ ООО «Лингвистический консалтинговый центр» провел **19–21 октября 2017 года** Международный саммит языков и культур. В рамках Саммита прошел ряд научных мероприятий: Международная конференция «И. А. Бодуэн де Куртенэ и мировая лингвистика», VIII Международная научно-практическая конференция «Сохранение и развитие родных языков в условиях многонационального государства: проблемы и перспективы», Международная научно-практическая конференция «Восток – Запад: литература и художественная культура», Международная научно-практическая конференция «Искусство и художественное образование в контексте межкультурного взаимодействия» симпозиумы «Клиническая лингвистика», «Современные технологии CLIL и CALL», «CEFR для национальных систем языковой оценки», «Современная тюркология: проблемы и перспективы», «Родные языки в поликультурной образовательной среде», «Литературная компаративистика», «Сохранение художественно-исторической среды современного города как духовного фактора культуры»

---

**8–11 ноября 2017 г.** в Институте международных отношений, истории и востоковедения Казанского (Приволжского) федерального университета состоялся VII Международный форум «Ислам в мультикультурном мире». В Форуме приняли участие ведущие ученые, представители Духовных управлений мусульман России, исламских вузов, медресе.

Организаторы конференции: Казанский (Приволжский) федеральный университет, Институт востоковедения Российской академии наук, Центр исламоведческих исследований Академии наук Татарстана, Духовное управление мусульман Российской Федерации, Духовное управление мусульман Республики Татарстан, Болгарская исламская академия, Российский исламский институт, Московский исламский институт

В рамках форума прошли Международная конференция «Мусульманские страны в системе современных международных отношений. Религия и государство на Ближнем Востоке: проблемы взаимодействия», Международная конференция «Проблемы дерадикализации молодежи на постсоветском пространстве», Мониторинг состояния мусульманской общины «Исламский радикализм в субъектах РФ» (памяти Е. М. Примакова), круглые столы «Актуальные проблемы тюркологии: Россия и тюрко-мусульманский мир», «История и текстология ислама», «Мусульманская городская цивилизация», круглый стол-презентация «Проблемы экономического развития Ближнего Востока», круглый стол памяти Ш. Марджани «Богословская и правовая мысль исламского мира».

*Материалы собраны и подготовлены Р. Н. Валиуллиным, постоянным представителем Республики Татарстан в Санкт-Петербурге и Ленинградской области; М. М. Хабутдиновой, кандидатом филологических наук, доцентом Института филологии и межкультурной коммуникации имени Льва Толстого Казанского федерального университета; Э. Х. Кадировой, кандидатом филологических наук, доцентом Института филологии и межкультурной коммуникации имени Льва Толстого Казанского федерального университета.*